РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево ул. Центральная, д.4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11. 2023 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Карар бирәм:

1. 2023 елның 22 ноябре 14.00 сәг. Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә, Яшьләр урамы, Яшьләр тыкрыгы;

2. 2023 елның 22 ноябре 15.00 сәг. Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Үзәк Һәм Мичурин урамнары буенча үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә;

3. 2023 елның 22 ноябре 16.00 сәг. Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Тукай, Чишмә, Степная урамнары һәм Степная тыкрыгы буенча үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә .

4. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урыны итеп Песәй авылы
Мәктәп тыкрыгы 3 йорт адресы буенча урнашкан Песәй авыл мәдәният йортын билгеләргә

Песәй авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

- Беренче этап: Яшьләр урамы 1 йорттан 28 йортка кадәр, Яшьләр тыкрыгы 3 йорттан 5 йортка кадәр
- Икенче этап: Мичурин урамы 1 нче номерлы йорттан башлап 27 нче номерлы йортка кадәр, Үзәк урамы 1 нче йорттан башлап 19 нчы номерлы йортка кадәр.
- Өченче этап: Тукай урамы 1 йорттан 37 йортка кадәр, Чишмә урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр, Степная урамы 1 йорттан 16 йортка кадәр, Степная тыкрыгы 1 йорттан 9 йортка кадәр.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтүчеләрне түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. вак таш сатып алу (китерү, тигезләү);
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
3. Песәй мәктәбе территориясендә агачларны кисү;
4. Мәктәп тыкрыгы буенча койма урнаштыру;
5. милли бәйрәм - Сабантуй үткәрү мәйданчыгында сәхнә кую.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И. Мөхәмматгалеев